РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Коморгузинского
сельского поселения
Атнинского муниципального
района
422758, с.Коморгузя, ул. Татарстана,
зд.40Б
Тел./факс.: (8-84369) 32022

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге
Советы
422758, Комыргуҗа авылы,
Татарстан урамы., 40Б нчы йорт
Тел./факс.: (8-84369) 32022

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» октябрь 2025 ел. № 3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2025 елның 07 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты 07 ноябрь 2025 ел 11.00 сәг.тән 12.00 сәг.кадәр;

- үткәрү урыны — Комыргуҗа авылы, Пионер урамы, 22 йорт, Комыргуҗа мәдәният йорты залы;

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 03 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Комыргуҗа авылы, Татарстан урамы, 40Б йорт;

- сайлау хокукына ия булган Төрекләр торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Төрекләр торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2."Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан,80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Төрекләр авылы территориясен яхшырту (территорияне чистарту - Төрекләр авылында үлән чабу).

2) Ремонтлау, коймалар кую, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (материаллар сатып алу, Төрекләр авылындагы зират өчен койма кую (контракт буенча эш өчен түләү, смета буенча); территорияне чистарту; зират, Төрекләр авылының үләннәрен чабу).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълумат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Комыргуҗа авылы, Татарстан урамы, 40Б йорт, Комыргуҗа авылы, Пионер урамы, 22 йортлардагы мәгълумат стендларында урнаштырырга.

3.Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ш.М.Шарипов